**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# Об отдельных мерах по защите прав и законных интересов ребенка в Республике Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 апреля 2022 года

## Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

1. Настоящий Закон регулирует правоотношения, возникающие в связи с реализацией основных гарантий прав и законных интересов ребенка в Республике Татарстан, в пределах полномочий, отнесенных законодательством Российской Федерации к полномочиям субъектов Российской Федерации.
2. Меры по предупреждению причинения вреда здоровью, физическому, интеллектуальному, психическому, духовному и нравственному развитию детей на территории Республики Татарстан установлены Законом Республики Татарстан от 14 октября 2010 года № 71-ЗРТ «О мерах по предупреждению причинения вреда здоровью детей, их физическому, интеллектуальному, психическому, духовному и нравственному развитию в Республике Татарстан».

## Статья 2. **Понятия, используемые в настоящем Законе**

Для целей настоящего Закона используются понятия, установленные Федеральным законом от 24 июля 1998 года № 124-ФЗ «Об основных гарантиях прав ребенка в Российской Федерации» (далее – Федеральный закон).

## Статья 3. **Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в области защиты прав и законных интересов ребенка**

1. К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан относятся:
1) законодательное регулирование в области защиты прав и законных интересов ребенка;

2) контроль за исполнением законодательства Республики Татарстан в области защиты прав и законных интересов ребенка;

3) иные полномочия, предусмотренные законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

2. К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан относятся:

1) утверждение государственных программ Республики Татарстан в области защиты прав и законных интересов ребенка;

2) установление порядка проведения оценки последствий принятия решения о реконструкции, модернизации, об изменении назначения или о ликвидации объекта социальной инфраструктуры для детей, являющегося государственной собственностью Республики Татарстан и (или) муниципальной собственностью, а также о реорганизации или ликвидации государственных организаций Республики Татарстан, муниципальных организаций, образующих социальную инфраструктуру для детей, включая критерии этой оценки, порядка создания комиссии по оценке последствий такого решения и подготовки ею заключений;

3) определение органа исполнительной власти Республики Татарстан, ответственного за разработку и утверждение списка рекомендуемых туристских маршрутов (других маршрутов передвижения) для прохождения группами туристов с участием детей в рамках осуществления самодеятельного туризма и для прохождения организованными группами детей, находящихся в организациях отдыха детей и их оздоровления, размещение указанного списка на официальном сайте органа исполнительной власти Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет»;

4) иные полномочия, предусмотренные законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 4. **Защита ребенка от информации, пропаганды и агитации, наносящих вред его здоровью, нравственному и духовному развитию**

Защита ребенка от информации, пропаганды и агитации, наносящих вред его здоровью, нравственному и духовному развитию, в том числе от национальной, классовой, социальной нетерпимости, от рекламы алкогольной продукции и табачных изделий, от пропаганды социального, расового, национального и религиозного неравенства, от информации порнографического характера, от информации, пропагандирующей нетрадиционные сексуальные отношения, а также от распространения печатной продукции, аудио- и видеопродукции, пропагандирующей насилие и жестокость, наркоманию, токсикоманию, антиобщественное поведение, осуществляется в соответствии с Федеральным законом и Федеральным законом от 29 декабря 2010 года № 436-ФЗ «О защите детей от информации, причиняющей вред их здоровью и развитию».

Статья 5. **Защита прав и законных интересов ребенка при формировании социальной инфраструктуры для детей**

1. Органы исполнительной власти Республики Татарстан при принятии решений по вопросам социально-экономического развития Республики Татарстан учитывают нормативы строительства объектов социальной инфраструктуры для детей. Указанные нормативы устанавливаются в соответствии с законодательством Российской Федерации и применяются с учетом особенностей Республики Татарстан, традиций народов Республики Татарстан, если иное не установлено законодательством Республики Татарстан.

2. Принятие органом исполнительной власти Республики Татарстан или органом местного самоуправления решения о реконструкции, модернизации, об изменении назначения или о ликвидации объекта социальной инфраструктуры для детей, являющегося государственной собственностью Республики Татарстан и (или) муниципальной собственностью, а также о реорганизации или ликвидации государственных организаций Республики Татарстан, муниципальных организаций, образующих социальную инфраструктуру для детей, допускается на основании положительного заключения комиссии по оценке последствий такого решения для обеспечения жизнедеятельности, образования, развития, отдыха и оздоровления детей, оказания им медицинской помощи, профилактики заболеваний у детей, их социальной защиты и социального обслуживания.

Порядок проведения оценки последствий принятия решения о реконструкции, модернизации, об изменении назначения или о ликвидации объекта социальной инфраструктуры для детей, являющегося государственной собственностью Республики Татарстан и (или) муниципальной собственностью, а также о реорганизации или ликвидации государственных организаций Республики Татарстан, муниципальных организаций, образующих социальную инфраструктуру для детей, включая критерии этой оценки, порядок создания комиссии по оценке последствий такого решения и подготовки ею заключений устанавливаются Кабинетом Министров Республики Татарстан.

3. Имущество, которое является государственной собственностью Республики Татарстан (земельные участки, здания, строения и сооружения, оборудование и иное имущество), которое относится к объектам социальной инфраструктуры для детей и возникновение, обособление или приобретение которого предназначено для целей образования, развития, отдыха и оздоровления детей, оказания медицинской помощи детям и профилактики заболеваний у них, социальной защиты и социального обслуживания детей, может использоваться только в данных целях.

Имущество, которое является собственностью Республики Татарстан и предназначено для целей образования, развития, отдыха и оздоровления детей, оказания медицинской помощи детям и профилактики заболеваний у них, социальной защиты и социального обслуживания детей, используется в порядке, определенном законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

4. Если государственная организация Республики Татарстан или муниципальная организация, образующая социальную инфраструктуру для детей,

сдает в аренду, передает в безвозмездное пользование закрепленные за ней объекты собственности, заключению договора аренды и договора безвозмездного пользования должна предшествовать проводимая учредителем в порядке, установленном частью 2 настоящей статьи, оценка последствий заключения таких договоров для обеспечения жизнедеятельности, образования, развития, отдыха и оздоровления детей, оказания им медицинской помощи, профилактики заболеваний у детей, их социальной защиты и социального обслуживания.

Договор аренды и договор безвозмездного пользования не могут заключаться, если в результате проведенной оценки последствий их заключения установлена возможность ухудшения указанных в абзаце первом настоящей части условий.

Требование о проведении оценки последствий заключения договоров, указанное в абзаце первом настоящей части, не распространяется на предусмотренные абзацем третьим пункта 4 статьи 13 Федерального закона случаи заключения договоров государственной или муниципальной профессиональной образовательной организацией, образовательной организацией высшего образования.

Статья 6. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань, Кремль
29 апреля 2022 года
№ 26-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 21 апрелендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм аның законлы мәнфәгатьләренең төп гарантияләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә барлыкка килүче хокук мөнәсәбәтләрен Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә Россия Федерациясе законнары белән кертелгән вәкаләтләр чикләрендә җайга сала.

2. Татарстан Республикасы территориясендә балаларның сәламәтлегенә, физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатларында «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – Федераль закон) билгеләнгән төшенчәләр кулланыла.

3 статья. **Бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә законнар белән җайга салу;

2) бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне тикшереп тору;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләр.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

2) Татарстан Республикасының дәүләт милке һәм (яисә) муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне, әлеге бәяләүнең критерийларын да кертеп, үткәрү тәртибен, мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү һәм аның тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибен билгеләү;

3) мөстәкыйль туризмны гамәлгә ашыру кысаларында балалар катнашында туристлар төркемнәре үтү өчен һәм балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмаларында булган балаларның оешкан төркемнәре үтү өчен тәкъдим ителә торган туристлар маршрутлары (хәрәкәтләнүнең башка маршрутлары) исемлеген эшләү һәм раслау өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын билгеләү, аны Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру;

4) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләр.

### 4 статья. **Баланы аның сәламәтлегенә, әхлакый һәм рухи үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан, пропагандадан һәм агитациядән яклау**

Баланы аның сәламәтлегенә, әхлакый һәм рухи үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан, пропагандадан һәм агитациядән, шул исәптән милли, сыйнфый, социаль түзеп тора алмаучанлыктан, алкоголь продукциясе һәм тәмәке әйберләре рекламасыннан, социаль, раса, милли һәм дини тигезсезлек пропагандасыннан, порнография характерындагы мәгълүматтан, традицион булмаган сексуаль мөнәсәбәтләрне пропагандалый торган мәгълүматтан, шулай ук көч куллануны һәм рәхимсезлекне, наркоманияне, токсикоманияне, үз-үзләрен тотышларын җәмгыятькә каршы куюны пропагандалый торган басма продукция, аудио- һәм видеопродукция таралудан яклау Федераль закон һәм «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 5 статья. **Балалар өчен социаль инфраструктура булдырганда бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклау**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше мәсьәләләре буенча карарлар кабул

иткәндә балалар өчен социаль инфраструктура объектларын төзү нормативларын исәпкә ала. Күрсәтелгән нормативлар Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә һәм, әгәр Татарстан Республикасы законнарында башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы үзенчәлекләрен, Татарстан Республикасы халыклары традицияләрен исәпкә алып кулланыла.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт милке һәм (яисә) муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү балаларның тормыш эшчәнлеген, аларга белем бирүне, аларны үстерүне, аларның ялын һәм аларны савыктыруны, аларга медицина ярдәме күрсәтүне, балалардагы авыруларны профилактикалауны, аларны социаль яклауны һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясенең уңай бәяләмәсе нигезендә рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасының дәүләт милке һәм (яисә) муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне, әлеге бәяләүнең критерийларын да кертеп, уткәрү тәртибе, мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү һәм аның тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Татарстан Республикасының дәүләт милке булып торган, балалар өчен социаль инфраструктура объектларына караган һәм төзелүе, аерымлануы яисә сатып алынуы балаларга белем бирүне, аларны үстерүне, аларның ялын һәм аларны савыктыруны тәэмин итү, балаларга медицина ярдәме күрсәтү һәм алардагы авыруларны профилактикалау, балаларны социаль яклау һәм аларга социаль хезмәт күрсәтү максатлары өчен билгеләнгән мөлкәт (җир кишәрлекләре, биналар, корылмалар һәм төзелмәләр, җиһаз һәм башка мөлкәт) әлеге максатларда гына кулланыла ала.

Татарстан Республикасының дәүләт милке булып торган һәм балаларга белем бирү, аларны үстерү, аларның ялы һәм аларны савыктыру, балаларга медицина ярдәме күрсәтү һәм алардагы авыруларны профилактикалау, балаларны социаль яклау һәм аларга социаль хезмәт күрсәтү максатлары өчен билгеләнгән мөлкәт Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә кулланыла.

4. Әгәр балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы яисә муниципаль оешма үзенә беркетелгән милек объектларын арендага бирсә, түләүсез файдалануга тапшырса, арендага бирү шартнамәсен һәм түләүсез файдалану шартнамәсен төзү алдыннан гамәлгә куючы тарафыннан әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән тәртиптә балаларның тормыш эшчәнлеген, аларга белем бирүне, аларны үстерүне, аларның ялын һәм аларны

савыктыруны, аларга медицина ярдәме күрсәтүне һәм балалардагы авыруларны профилактикалауны, аларны социаль яклауны һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен мондый шартнамәләр төзүнең нәтиҗәләрен бәяләү үткәрелергә тиеш.

Арендага бирү шартнамәсе һәм түләүсез файдалану шартнамәсе, аларны төзү нәтиҗәләренә үткәрелгән бәяләү нәтиҗәсендә әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән шартларның начарлануы мөмкинлеге билгеләнсә, төзелә алмый.

Әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән шартнамәләр төзү нәтиҗәләренә бәяләү үткәрү турында таләп Федераль законның 13 статьясындагы 4 пунктының өченче абзацында каралган дәүләт яисә муниципаль һөнәри белем бирү оешмасы, югары белем бирү мәгариф оешмасы белән шартнамәләр төзү очракларына кагылмый.

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 29 апрель
№ 26-ТРЗ